
Галим, З. Тукайны бергә укыйбыз! [Габдулла Тукайның тууына 140 ел тулу уңаеннан «Тукайны бергә укыйбыз» дип исемләнгән проект турында] / З. Галим. – Текст : турыдан-туры, электрон // Шәһри Чаллы. – 2026. – № 5 (28 гыйнвар). – Б. 2. – URL: https://shahrichalli.ru/news/kich-bgen-irtg/tukainy-berga-ukyibyz. – Чыгу вакыты: 27.01.2026.

# Тукайны бергә укыйбыз!




**Татар халкының бөек шагыйре Габдулла Тукайның тууына 140 ел тулу уңаеннан, Чаллыда «Тукайны бергә укыйбыз» дип исемләнгән проектка старт бирелде.**

Үзәкләштерелгән китапханәләр челтәре директоры Венера Гайнуллина әйтүенчә, бу проектны Татарстан мәдәният министрлыгы оештыра.

«Без бу чарага теләп кушылдык. Һәр атнаның пәнҗешәмбе көнендә китапханәләрдә Тукайга багышланган әдәби очрашулар үтә. Анда аның әсәрләре укыла. Бу чарада теләгән һәркем катнаша ала. Шулай ук Тукай шигырьләрен укып, видео төшереп китапханәләргә дә җибәреп була», – диде ул.